РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АЛЬМЕТЬЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ӘЛМӘТ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«28» июль 2026 ел г. Альметьевск № 1361

**Әлмәт муниципаль районы Башкарма комитетының «Әлмәт муниципаль районы территориясендә стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыру схемасын раслау турында» 2024 елның 1 ноябрендәге 3579 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

«Россия Федерациясе сәүдә эшчәнлеген дәүләти җайга салу нигезләре турында» 2009 елның 28 декабрендәге 381-ФЗ номерлы Федераль законның 10 статьясын гамәлгә ашыру максатларында, Әлмәт муниципаль районы Советының «Әлмәт муниципаль районы Муниципаль берәмлегенә җирле әһәмияттәге аерым мәсьәләләрне хәл итү буенча Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Әлмәт шәһәре муниципаль берәмлеге вәкаләтләренең бер өлешен гамәлгә ашыру буенча» Әлмәт шәһәр Советы тәкъдимен кабул итү турында» 2021 елның 28 сентябрендәге 79 номерлы карары, Әлмәт муниципаль районы Башкарма комитетының «Әлмәт муниципаль районы территориясендә стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыру тәртибе турында нигезләмәне раслау хакында»2024 елның 22 апрелендәге 1579 номерлы карары нигезендә, Әлмәт муниципаль районы халкына сәүдә хезмәте күрсәтүне оештыруны һәм сыйфатын яхшырту өчен шартлар тудыру максатларында

БАШКАРМА КОМИТЕТ КАРАР БИРӘ:

1. Әлмәт муниципаль районы Башкарма комитетының «Әлмәт муниципаль районы территориясендә стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыру схемасын раслау турында» 2024 елның 1 ноябрендәге 3579 номерлы карарына (Әлмәт муниципаль районы Башкарма комитетының 2025 елның 29 октябрендәге 2610 номерлы карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

Әлмәт муниципаль районы территориясендә стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыру урыннары исемлегендә карарның 1 нче кушымтасында:

1 пунктның 3 графасында «азык-төлек продуктларын» сүзләрен «аяк киемен ремонтлау» сүзләренә алмаштырырга;

26 пунктны төшереп калдырырга.

заказ № 4553-940

2. Әлеге карарны «Альметьевский вестник» газетасында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (PRAVO.TATARSTAN.RU) урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны район Башкарма комитеты җитәкчесенең икътисад буенча урынбасары А. Ә. Ямалетдиновка йөкләргә.

Район
Башкарма комитеты җитәкчесе А.М. Каюмов